СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**16 октябрь 2020 ел** **№ 19**

**Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 331 номерлы «Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү һәм класс чиннары бирү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (10.11.2015, № 17, 10.11.2016, №81, 14.03.2020, № 237, 19.09.2019, № 270, 20.05.2020, №329 үзгәрешләр белән)**

Кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү комиссиясе эшчәнлеген оештыруны камилләштерү, класс чиннары бирү өчен квалификация имтиханнары кабул итү, муниципаль хезмәттә эш стажын билгеләү һәм елларны исәпләү буенча комиссия эшен камилләштерү максатыннан Арча район Советы карар бирде:

1. Арча район Советының 24.04.2015 ел, №331 карары белән расланган "Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү һәм класс чиннары бирү турында" карары белән расланган (10.11.2015 ел, №17, 10.11.2016, №81, 14.03.2020 ел, № 237, 19.09.2019 ел, № 270, 20.05.2020 ел, №329 үзгәрешләр белән) Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү, класс чиннары бирү өчен квалификация имтиханнары кабул итү, муниципаль хезмәттә эшләгән елларны исәпләү буенча эш стажын билгеләү буенча комиссия составын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары А.Ф. Мөхәммәтовага йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
16 октябрь 2020 ел, № 19
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү, класс чиннары бирү өчен квалификация имтиханнары кабул итү, муниципаль хезмәттә эшләгән елларны исәпләү буенча эш стажын билгеләү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Мөхәммәтова Алсу Фирдәүсовна | - Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе; |
| Галимуллин Радик Наилевич | - Арча район Советы аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары; |
| Хәкимҗанова Альбина Фәритовна | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының кадрлар секторы мөдире, комиссия секретаре |
| ***Комиссия әгъзалары*** | |
| Гапдерахманова Гүзәл Әдһәмовна | - Арча район Советы аппаратының оештыру-гомуми бүлеге башлыгы; |
| Галимова Светлана Петровна | - "ТР Арча муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы" МКУ җитәкчесе; |
| Сәгыйтова Ләйсән Гарәфетдиновна | - Арча район Советы аппаратының юридик мәсьәләләр буенча бүлеге башлыгы; |
| Сафиуллин Айдар Габделфәртович | - Г.Тукай исемендәге Арча педагогика көллиятенең информатика һәм математика укытучысы, ИКТ буенча директор урынбасары (килешү буенча). |

Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары А.Ф. Мөхәммәтова